КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 декабрь г.Казань № 1169

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы мәсьәләләре» 2011 ел, 6 июнь, 460 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы мәсьәләләре» 2011 ел, 6 июнь, 460 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 26 март, 189 нчы; 2016 ел, 16 июнь, 407 нче; 2016 ел, 19 август, 572 нче; 2016 ел, 27 октябрь, 789 нчы; 2018 ел, 31 июль, 621 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1142 нче; 2019 ел, 18 март, 188 нче; 2020 ел, 2 март, 158 нче; 2020 ел, 13 май, 382 нче; 2020 ел, 7 август, 665 нче; 2021 ел, 2 март, 114 нче; 2021 ел, 28 июнь, 503 нче; 2021 ел, 9 сентябрь, 852 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.1.11 пунктча өстәргә:

«2.1.11. Татарстан Республикасында яңа инвестиция проектларын эзләү.»;

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.1.40 пунктча өстәргә:

«4.1.40. Инвесторлар белән үзара хезмәттәшлек итү, инвестицияләр җәлеп итү һәм инвестиция проектларын тормышка ашыру мәсьәләләре буенча иң яхшы тәҗрибәләрне кулланышка кертү буенча тәкъдимнәр әзерли.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В. Песошин